ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 453-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 453-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2043-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына**
**үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $44^6$ статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне бүлү әлеге Кодексның $9^3$ нче кушымтасында китерелгән методика буенча башкарыла.»;

2) $9^3$ нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасының
Бюджет кодексына
$9^3$ нче кушымта

**«Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә гомуми**

**юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне бүлү методикасы**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләрне (алга таба – субвенцияләр) бүлү «Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) финанс белән тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

2. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме түбәндәге ($C_{svod}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{svod} = \sum_{i=1}^{n} C_{i\ присяжн.}$$

монда:

$C_{i\ присяжн.}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга тиешле муниципаль район, шәһәр округы (алга таба – i-муниципаль берәмлеге) бюджетына бирелә торган субвенция күләме;

n – дәүләт вәкаләтләре бирелгән муниципаль берәмлекләр саны.

3. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме ($C_{iприсяжн.}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{iприсяжн.} = C_{iрасч.} + C_{iрезерв} - C_{iост.},$$

монда:

$C_{iрасч.}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бирелә торган субвенция буенча i-муниципаль берәмлегенең исәпләнгән ихтыяҗы;

$C_{iрезерв}$ – чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бүленмәгән резервтан әлеге Методика нигезендә i-муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче тарафыннан бүлеп бирелә торган акчалар;

$C_{iост.}$ – i-муниципаль берәмлеге бюджетында алдагы ел азагына файдаланылмый калган акчалар.

4. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бирелә торган субвенция буенча i-муниципаль берәмлегенең исәпләнгән ихтыяҗы ($C_{i\text{расч.}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{i\text{расч.}} = P_{i\text{канц.}} + P_{i\text{почт.}} + P_{i\text{сми}},$$

монда:

$P_{i\text{канц.}}$ – i-муниципаль берәмлегенең канцелярия чыгымнары күләме;

$P_{i\text{почт.}}$ – i-муниципаль берәмлегенең почта чыгымнары күләме;

$P_{i\text{сми}}$ – i-муниципаль берәмлегенең Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен (алга таба – кандидатлар исемлекләре) массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруга бәйле чыгымнары күләме.

5. I-муниципаль берәмлегенең канцелярия чыгымнары күләме ($P_{i\text{канц.}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{i\text{канц.}} = H_{\text{канц.}} \times Ч_i \times И_{\text{пц}},$$

монда:

$H_{\text{канц.}}$ – бер кандидатка 10 сумнан артыграк булмаган күләмдә билгеләнгән канцелярия чыгымнары өчен финанс чыгымнары нормативы;

$Ч_i$ – i-муниципаль берәмлегендә суд рәисләре заявкалары буенча кандидатлар исемлекләренә кертелергә тиешле йә i-муниципаль берәмлегендә присяжный утырышчылар булу хокукын югалткан (исемлекләрне үзгәрткән очракта) гражданнарның исәпләнгән саны;

$И_{\text{пц}}$ – чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турында федераль закон нигезендә инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып, куллану бәяләре арту индексы.

6. I-муниципаль берәмлегенең почта чыгымнары күләме ($P_{i\text{почт.}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{i\text{почт.}} = H_{\text{почт.}} \times Ч_i \times И_{\text{пц}},$$

монда:

$H_{\text{почт.}}$ – бер кандидатка 50 сумнан артыграк булмаган күләмдә билгеләнгән почта чыгымнары өчен финанс чыгымнары нормативы.

7. I-муниципаль берәмлегенең кандидатлар исемлекләрен массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруга бәйле чыгымнары күләме ($P_{i\text{сми}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{i\text{сми}} = H_{i\text{сми}} \times K_{i\text{сми}},$$

монда:

$H_{i\text{сми}}$ – массакүләм мәгълүмат чараларында кандидатлар исемлекләрен бастыру өчен бер басма табак бәяләренең Татарстан Республикасында кабул ителгән уртача дәрәҗәсе;

$K_{i\text{сми}}$ – i-муниципаль берәмлегендә кандидатлар исемлекләренең басма табаклар саны.

8. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә беренче тапкыр бүлгәндә расланган дәрәҗәдән тыш дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләргә өстәмә ихтыяҗ барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче тарафыннан бүленмәгән резервтан акчалар бүлеп бирелә.

Резервны бүлү ($C_{i резерв}$) түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$C_{i резерв} = C_{i уточн.} - C_{i расч.},$$

монда:

$C_{i уточн.}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенциягә і-муниципаль берәмлеге заявкасы буенча төгәлләштерелгән (Россия Федерациясе Югары Суды каршындагы Суд департаменты эшләгән тәртип нигезендә) ихтыяҗ.

Әгәр $C_{i уточн.}$ $C_{i расч.}$ дән кимрәк булса, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенция і-муниципаль берәмлеге бюджетына заявка нигезендә күчерелә, ә Татарстан Республикасы бюджетыннан соратылмый калган акчалар суммасы муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетлары арасында алга таба яңадан бүлү өчен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бүленмәгән резервны арттыруга җибәрелә.

9. Заявкалар саны чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган субвенцияләр суммасыннан артык булган очракта, ассигнованиеләрне бүлү ($C_{i присяжн.уточн.}$) түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$C_{i присяжн.уточн.} = C_{svod} / C_{svod\ уточн.} \times C_{i уточн.},$$

монда:

$C_{svod\ уточн.}$ – барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округлары буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләргә төгәлләштерелгән ихтыяҗ.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезләмәләрен «Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субвенцияләрне бүлү методикасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актының, актының аерым нигезләмәсенең үз көчен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 24 октябрендәге 1894 номерлы карарына (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) туры китерү максатларында эшләнде.

Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субвенцияләрне бүлүнең яңа методикасы расланды.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 140 статьясы нигезендә финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе субъекты бюджетына субвенцияләр булган җирле бюджетларга Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан субвенцияләрне бүлү турындагы нигезләмәләр өлешендә методикалар Россия Федерациясе Бюджет кодексының 133 статьясы нигезендә федераль законнар һәм (яисә) Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актлары, һәм (яисә) Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актлары белән раслана торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү һәм Россия Федерациясе субъектлары арасында бүлү тәртипләренең таләпләренә туры килергә тиеш.

Закон проекты белән «Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган вәкаләтләрнең исеме төгәлләштерелә. Шулай ук федераль норматив хокукый җайга салуны исәпкә алып, Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне бүлү методикасы кергән Татарстан Республикасы Бюджет кодексына $9^3$ нче кушымта яңа редакциядә бәян ителә.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми. Гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү чыганагы булып федераль бюджеттан субвенцияләр тора.